# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ
## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбьяз авыл җирлеге Дөбьяз торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

06 декабрь 2021ел                                                                 № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2021 елның 4 нче декабрь 14 сәгать 00 минутта, 2021 елның 5 нче декабрь 14 сәгать 00 минутта, 2021 елның 6 нче декабрь 14 сәгать 00 минутта уздырылган “Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбьяз авыл җирлеге Дөбьяз авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?” дигән мәсьәлә буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде:

а) Дөбъяз авылы эчендәге асфальт юлларны ямауга юллау, б) Авдеев урамында юлны вак таш белән түшәүгә.

«РИЗА»                                        «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 1430 (бер мең дүрт йөз утыз) кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 803 (сигез йөз дә өч) кеше, бу 56 % ны тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында 803 (сигез йөз дә өч) катнашучы тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 (ноль) кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены түбәндәгечә хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбьяз авыл җирлеге Дөбьяз торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2022 елда үзара салым акчасын яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Дөбьяз авыл җирлеге Дөбьяз торак пункты территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә кертергә.

3. Жыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлтергә: а) Дөбъяз авылы эчендәге асфальт юлларны ямауга юллау, б) Авдеев урамында юлны вак таш белән түшәүгә.

4. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Р.Ш.Галиуллин